

Ниһаять, жәйнен беренче декадасын вакладык. Авылларда ара-тирә моточалгы тавышлары ишетелә. Ин тынгысыз, олгер хужа малларына кондәлек vләм печәнне чабып ашата. Быел, ел фасыллары вакыт тошенчәсен шактый бутады шул: чын кыш житкәнен котә-котә, кыш vтеп беткәнен, чын яз килгәнен котә-котә, яз vтеп беткәнен дә сизми калдык. Инде жәй ае керде, тик Саранскта боз да явып алырга олгерде. Иртә килгән рәвеш ясап, игенчеләрне кырга чыгарган яз шактый сюрпризлар белән кырдагыларга vп кенә остәмә мәшәкатьләр тудырды. Санаулы кондә бетәргә тиешле эшләр апрель-май аена сузылды. Шул сәбәп белән язгы эшләр печән остенә кушыла язды. Кайбер елларда район хужалыклары май азагында печәнгә тошә иде. Быел республикабыз предприятиеләре терлек азыгы әзерләvгә керештеләр, ә бортекле-кузаклы культуралар чәчvне тогәллиләр. 26 май торышына республиканын Атяшевский, Атюрьевский, Зубово-Полянский, Ичалковский, Ковылкинский, Кочкуровский, Лямбирский, Рузаевский, Торбеевский һәм Октябрь районнары куелган бурычларны йоз процентка vтәгән. Тулаем Мордовиядә чәчv тогәлләнеп килә – 26 майга алынган мәгълvматларга караганда, язгы чәчv 389,4 мен га мәйданда – 84% мәйданда башкарылган, шулардан бортекле һәм кузаклы культуралар 267,4 мен га мәйданда чәчелгән, бу план кvрсәткеченен 97%ын тәшкил итә. Бортекле культуралардан тыш, аграрийлар 19,3 мен га (планнын 92% ы): рапс (11,9 мен га яисә 50%), ашлык кукурузын (21,1 мен га яисә планнын 67,4% ы) чәчәләр.

Республикада беренчеләрдән булып ООО «Магма ХД» беренче катындагы vләннәрдән азык (витаминно-травяная мука) әзерләvгә керештеләр. Якын арада Ләмберә, Инсар һәм Рузаевка районнары хужалыклары терлек азыгы әзерләvгә керешергә планлаштыралар, янгырлар комачауламаса. 2020-2021 елларда терлек азыгы белән тәэмин итv очен республика хужалыкларына кимендә 95 мен тонна печән, 605 мен тонна сенаж һәм 810 мен тонна силос әзерләргә кирәк, икән.

Кvпьеллык vләннәрне иртә жыеп алу, әзерләv технологиясен vтәгәндә, югары эчтәлеге булган органик матдә (1 кг коры матдә), протеин микъдары югары булган (1 кг коры матдә) һәм югары энергетика кыйммәте булган азык алырга момкинлек бирә. Мондый сенаж алу рационнарда кыйммәтле аксым азыгын куллануны киметергә момкинлек бирәчәк.

Сонгы янгырлар һәм берничә конлек жылылар печәннәрнен vсешен, олгере- шен тизләтте. Башка елларда, конгә ничәшәр сантиметр vсә икән дип, печән басуларына линейкалар куя иделәр, быел алай мәшәкатьләнәсе дә булмады, кvрер кvзгә vк сизелә. Мондый һава шартлары vләннәрне колагыннан тартып vстерә. Берьеллык, кvпьеллык vләннәр матур булып олгереп килә. Терлек азыгын әзерли башларга ин унай вакыт. Кыш

буе малларга югары сыйфатлы, энергияле азык ашатам дисән, аны әзерләvгә иртәрәк керешергә кирәк. Ни очен дигәндә, vләннәрне чәчәк атар алдыннан чабып алганда, печән составында файдалы матдәләр кvбрәк була, сонга калып жыйганда vләннен файдалылыгы 40 – 50 процентка кадәр кими. Шуна кvрә кvмәк хужалык житәкчеләре белгечләренә менә шуны истә тотып эш оештырырга, кvләм дип, печәннен калынайганын котәбез дип, сыйфат мәсьәләсен икенче планга калдырмаска куштылар.
Хәзер менә шулай – авылларда печән осте дигән сvз кvмәк хужалыклар очен vзгә бер жаваплы кампания булып кына калды, гади кешеләр авызыннан ишетелми дә диярлек. Безнен ише буын кvнелендә генә анын белән бәйле матур да, борчулы да хатирәләр саклана. Ни генә дисән дә, читтән караганда гына романтика шул печән осте. Әйе, хәзер инде авылларда, элекке кебек, чалгы чvкеп, селтәнеп печән чабу дигән нәрсә ботенләй юк. Капка тобендәге оч бортек vләнне чабар очен дә авыл кешесе бензинлы чалгысын кабыза. Элекке бәрәнге бакчаларын биләгән печән жирләрен дә, шәхси тракторы булганнарга әйтә дә чаба, тарата, әйләндерә, тvкли, торгәкли торган тагылмалары белән (печәненә әнә шулай кулын да тигезмәvчеләр бар) басуда ук эшен бетереп алып кайта. «Чvмече-сәнәге» булган тагын бер тракторчы әлеге торгәкләрне печәнлеккә менгереп бирә. Авыл кешесенен дә, газапланмыйча, момкин кадәр эшен жинеләйтергә тырышуы һәм елдан-ел жинеләйтv әмәлен табуы бермә-бер соендерә. Әмма бергәләп печән чабып жыюлар, vзенен мәшәкате белән, матур да, истәлекле дә иде.

**Наилә НАСЫРОВА**